Мәкаләдә энциклопедист галим Нәкый Исәнбәтнең (1899–1992) хезмәтләрендә яктыртылган концепция тасвирлана. Эзләнү материалы булып, язучының җәдитчелеккә багышланган мәкаләләре тора. 1930–1950 нче елларда үзенең карашлары аркасында Н. Исәнбәт күп тапкырлар хакимият тарафыннан төрле эзәрлекләүләргә дучар ителә. Язучы өстән төшерелгән җәдитчелек концепциясен ачык тәнкыйть итүдән дә курыкмый. Н. Исәнбәтнең җәдитчелек турындагы мәкаләләре – милләт зыялыларының иҗтимагый-мәдәни тормышны либерализацияләү турындагы өметләре ул.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, татар халкы тарихы, татар җәдитчелеге, Нәкый Исәнбәт, зыялылар, интеллигенция һәм хакимият.

Катгый идеологик контроль елларында Нәкый Исәнбәт берничә тапкыр милли тарихны бердәйләштерү, бердәм нормага китерүгә, ягъни унификациягә каршы чыга. Галимнең бу каршы фикере исә иң югары дәрәҗәдәге тикшерүләргә дучар ителә. Галимнәр игътибарының үзәгенә аның тормышындагы өч «дөнья шаулаткан тарих»: «Җидегән» эшчәнлеге белән бәйле кулга алыну, ВКПб Үзәк комитетының 1944 елның 9 августы «Идегәй» эпосы турындагы карары, КПСС Татар өлкә комитеты бюросының 1953 елның 30 ноябрендәге «Миркәй һәм Айсылу» карары куела [Султанбеков], [Тагиров], [Госманов], [Хаплехамитов], [Хабутдинова].

1944 елдан Н. Исәнбәтне «Татар АССР тарихын сурәтләүдә милли характердагы хаталар җибәрүче» (Алтын Урданы бизәкләп, чуарлап күрсәтүче, «Идегәй» хан-феодал эпосын популярлаштыручы) язучы итеп бәяли

башлыйлар. Тикшерүләргә сәбәп булып, «Идегәй» эпосыннан бигрәк, язучының «Татар халык «Идегәй» эпос-дастанының 500 еллыгы» дигән мәкаләсе тора. Бу мәкаләне Шафиков үзенең доклад язуында «ялгыш, хата» дип атый [Шафиков]. ВКП(б) Үзәк комитетының 1944 елның 9 августы карарында [Постановление ЦК ВКП(б) от 9 августа 1944 г.] Н. Исәнбәт исеме турыдан-туры телгә алынмаса да, язучы дистәләрчә елларга сузылган эзәрлекләүләргә дучар була.

1953 елда Н. Исәнбәтне җәдитчелекне яклауда, аны мәгърифәтчелек белән тәңгәлләштерүдә, шулай ук ВКП(б) Татар өлкә комитетының «Татар урта мәктәпләренең 8 сыйныф әдәбият дәреслегендәге хаталар» турындагы карарын игътибарсыз калдыруында гаеплиләр. «Миркәй һәм Айсылу» әсәре тирәсендәге бәхәсләр исә Татар өлкә комитеты бюросының «Н. Исәнбәтнең пьесалар җыентыгындагы идеологик бозыклыклар» дигән карар кабул итүенә китерә. 1953 елның 30 ноябрендәге язучылар, композиторлар һәм театр хезмәткәрләренең шәһәр җыелышында язучының һаман да буржуаз-милләтче позициясендә кала бирүен исенә төшерәләр. 1954 елның 18 февралендә ТАССР Язучылар Союзы идарә утырышында Г. Халит Н. Исәнбәтне җәдитчелекнең асылын аңламауда, ә Г. Бәширов җәдитчелек мәсьәләсен «үзенчә» буташтыруда гаепли [Хаплехамитов, С. 54-59].

Тикшеренүебезнең максаты – Н. Исәнбәтнең җәдитчелек мәсьәләсенә булган карашларын өйрәнү. Анализланачак материал ролен язучы архивында саклана торган 2 мәкалә кульязмасы үти [Исәнбәт, Мәгърифәт–җәдид], [Исәнбәт, Җәдитчелек]. Кызганыч, кульязмаларның язылу вакыты күрсәтелмәгән. Шулай да аларның 1960 нчы еллар уртасында язылганлыгын фаразлап була, чөнки мәкаләләрдә КПСС ның XXII съезды (1961 елның 17–31 октябре) һәм 1917 елгы Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгы (1967) телгә алына. «ТАССР совет язучылар берлеге идарәсе утырышының (18.02.1954) 5 номерлы протоколы» Н. Исәнбәтнең җәдитчелек турындагы 1950 – 1960 еллардагы бәхәсләрнең актив катнашучысы булуын дәлилли [Хаплехамитов, С. 137-142].

Җәдитчелеккә багышланган 1930 – 1960 елгы тикшеренүләргә историографик анализ аларның сәясәтләштерүгә дучар ителүләрен, моның исә үз чиратында милли хәрәкәтләрне юкка чыгару һәм партия-дәүләт контролен көчәйтүгә юнәлгән көрәш белән бәйле булуын дәлилли. ТАССР да җәдитчелекнең контрреволюцион буржуаз-милли агым «булуын» фаш итүгә юнәлтелгән хәрәкәт 1940 елның ахырында башланып китә [Мухаметов], [Революция 1905-1907...], [Гайнуллин], [Фасеев]. Иң югары ноктасына ул 1952 елда җитә, бу вакытта ВКП(б) Татар өлкә комитеты бюросының «Татар урта мәктәпләренең 8 сыйныф әдәбият дәреслегендәге хаталар» турындагы карарына (1952 елның 18 гыйнвары) кул куела, һәм җәдитчелек «буржуаз-милли хәрәкәт» дип бәяләнә [Из постановления, С. 861]. Җәдитчелекнең яңа билгеләмәсе «ябык ишекләр» артында кабул ителә һәм, Н. Исәнбәт фикеренчә, «өстән» массаларга төшерелә, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гыйльми оешмаларда фикер алышмыйча, көчләп тагыла. [Исәнбәт, Җәдитчелек, Б. 28].

Үз мәкаләләрендә Н. Исәнбәт җәдитчелек мәсьәләсенә багышланган фәнни әдәбиятка анализ ясамый диярлек. Совет хакимиятенең беренче елларында җәдитчелеккә бирелгән тәфсилле бәягә ишарәләгәндә, мәкалә авторы Җамал Вәлидинең «Очерки истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.)» (1923) [Валиди] хезмәтен күздә тота булса кирәк. Анда җәдитчелек төп максаты Европа мәдәнияте белән якынаю булган «үзенчәлекле акыл-мәдәният хәрәкәте буларак» тасвирлана. Бигрәк тә Н. Исәнбәт җәдитчелекне прогрессив күренеш итеп сурәтләгән Г. Ибраһимов (К. Насыйри, Ш. Мәрҗани, «Галия» мәдрәсәсе турындагы мәкаләләр) һәм Г. Сәгъди («Татар әдәбияты тарихы») хезмәтләрен аерып күрсәтә [Исәнбәт, Җәдидчелек, Б.10]. Ул Г. Гайнуллин хезмәтен нык тәнкыйть утына сала [Гайнуллин]. Оппонентларын Н. Исәнбәт исә «җәдитчелекне инкяр итүче иптәшләр» дип атый. Анализ ясау вакытында башка хезмәтләргә игътибар итмәүләрен, ул аларның түбән сыйфатлы булулары белән аңлата: «алар шулкадәр түбән сорт вульгар социологизмнан гыйбарәт, бернинди тәнкыйтьне дә күтәрерлек түгел». Н. Исәнбәт фикеренчә, бу хезмәтләрнең авторлары «үзләре хәл итәргә алган җәдитчелек-мәгърифәтчелек хәрәкәтенең асылын да, затын да, аны урын ягыннан да, заман ягыннан да, аның милли составын да, сыйфый-иҗтимагый тенденцияләрен дә, кемгә каршы юнәлүен дә, җәдите дә, кадиме дә, кыскасы, бер генә моментын да дөрес ачыклый алмыйлар. Берсе хакында да бер генә (30) дөрес мәгълүмат та

бирә алмыйлар» [Исәнбәт, Җәдитчелек, С.29-30].

Татар мәдәнияте тарихын бозып сурәтләүгә каршы килеп, галим КПСС ның Татар өлкә комитетына гариза яза, ике тапкыр обком секретаре С.Г. Батыев белән көрешә. «Партия Үзәк комитеты үз карарында Н. Исәнбәтнең тупас сәяси хаталарына, аның «Идегәй» пьесасы белән бәйле тарихны сурәтләүдәге буржуаз-милләтчел бозыклыкларына төртеп күрсәтә. Р. Ишморатов Н. Исәнбәтне үз хаталарын танымауда һәм элеккечә буржуаз-милләтчел позициядә калуында гаепли, бу хакта аның яңа пьесалар җыентыгы хәбәр итә, дип саный».

Язучыга каршы Кави Нәҗми чыгыш ясый. Ул «драматург Н. Исәнбәтнең милләтчел тенденцияләрен» кискен тәнкыйть итә. Гази Кашшаф исә «эчтәлеге белән бозык булган» «Миркәй һәм Айсылу» пьесасының Татар дәүләт академия театрын кызыксындыруына аптырый. КПСС өлкә комитеты секретаре С. Батыев «партия Үзәк комитетының 1944 елгы карарының барлык язучылар һәм, гомумән, ТАССР мәдәният хезмәткәрләре өчен программа документы булуын» һәркемнең исенә төшерергә тырыша. Үз чыгышында ул Н. Исәнбәткә булган гаепләмәләрен киңәйтә һәм төгәлләштерә. Республика хакимияте язучының җәдитчелеккә биргән бәясе белән канәгать булмавын белдерә һәм аны «милләтчел идеяләрне геройларының репликалары аша үткәрергә» тырышуда гаепли. Шау-шу әсәрдәге бер геройның авылдашларына «мөселман кардәшләр» дип эндәшүеннән соң башлана. С. Батыев бу эндәшүне милләтчеләрнең лозунгы буларак бәяли. КПСС өлкә комитеты секретаре Н. Исәнбәтнең Ш. Мәрҗани шәхесен бәяләае белән дә канәтьсез кала. Аңа «реакционер»ның мәкаләдә мәгърифәтче буларак сурәтләнүе ошамый (тулырак [Хаплехамитов]). 1953 елда «Миркәй һәм Айсылу» драмасын нәшер итү белән бәйле гаугадан соң, язучы «хакыйкать» һәм яклау эзләп, Мәскәүгә мөрәҗәгать итә.Ул Н. С. Хрущёвка гариза яза һәм «Н. Исәнбәтнең пьесалар җыентыгындагы идеологик бозыклыклар» дигән карарны (ноябрь, 1953) кире кагуга ирешә.

Н. Исәнбәтнең җәдитчелек турындагы мәкаләләрендә совет җәмгыятенең десталинизация курсын дәвам итү, татар мәдәниятенең элекке кыйммәтен кайтару чагылыш таба. Галим җәдитчелеккә дискредитация ясарга омтылган партия галимнәренең күпләгән ялганнарына, фальсификацияләренә каршы чыга: «Иң элек аны мәгърифәтчелектән аералар. Аннары, җәдитчелек ул империализм чорында туган саф буржуаз хәрәкәт, аның эчтәлеге, менә күрәсез, панисламизм һәм пантюркизмнан гыйбарәт, ә мәгърифәтчелек исә ул революцион-демократик /?/ хәрәкәт[1], бу нәрсәләр, ут белән су кебек, бер-берсе белән сыеша алмый, диләр. Һәм шул ясалма тезисны исбатлау өчен, татар иҗтимагый тарихындагы барлык революцион демократия вәкилләрен /гәрчә бу вәкилләр күпчелек очракта үзләрен җәдитче дип кычкырып торсалар да/ барын да көчләп мәгърифәтчеләр дип атап, калган барлык реакцион элементларны җәдитчеләр дип исемлиләр» [Исәнбәт, Җәдитчелек, Б.4 ]. Галим татар зыялыларының, үзләрен әллә кайчан җәдитчеләр дип игълан иткән язучылар (М. Гафури, Г. Ибраһимов, Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Ш. Әхмәдиев, К. Тинчурин, Ф. Сәйфи, М. Фәйзи, Һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, М. Максуд, Ә. Фәйзи һ.б.) фикерләренең игътибарсыз калуына да ачулана.

Бу терминның татар дөньясында яшәү тарихы турында уйланып, Н. Исәнбәт болай яза: «Җәдит – яңа, ысулы җәдит – яңа метод дигән сүз. Бу сүз башта 1890 нчы елларда элекке иске татар мәктәпләрендә иҗек ысулы белән гарәп әлифбие, укуны ташлап, ана телендә аваз методы яңа әлифба буенча уку дигән мәгънәдә тормышка куллануга кереп киткән. Шуннан бу сүз киңрәк мәгънә хасыйл итеп, гомумән, мәктәп-мәдрәсәләрдә дини схоластика уку урынына, ана телендә башлангыч фәннәр кертү һем уку методларын үзгәртү, гомумән тормышта, культуралашу, европалашу мәгънәсендә җәдитләшү /яңару/ дигәнне аңлатып киткән. Менә шуннан бу хәрәкәтне алып баручылар да җәдитчеләр дә элекке урта гасыр методлары белән тормыш һәм мәктәп-тәрбия эшләрен алып баручылар да кадимчеләр дип аталганнар». [Исәнбәт, Җәдитчелек, Б. 6-7].

Н. Исәнбәт буржуазия мохитендә туган татар җәдитчелегенең милли үзенчәлеге идеясен хуплый. Галим фикеренчә, бу хәрәкәтне, иҗтимагый һәм социаль тормыштагы аермаларга бәйле, француз, алман мәгарифе һәм рус мәгърифәтчелеге белән тәңгәлләштерү дөрес түгел дип уйлый. Аның фикеренчә, татар җәдитчеләре, татар мәдәнияте һәм мәгърифәтен яңартырга, модернизация-

[1] Мәсәлән, Гайнуллин хезмәтләре каралсын.

ләргә теләп, урта гасыр дини фанатизм һәм артта калганлык тарафдарларыннан торган кадимчелек белән көрәш алып бара [Исәнбәт, Җәдитчелек, Б. 8].

Татар җәдитчелегенең үзенчәлеген Н. Исәнбәт татарларда милли мәгариф системасының дәүләт тарафыннан контрольдә тотылмавында һәм матди яктан тәэмин ителмәүдә күрә. Шуңа күрә мәгърифәт мәсьәләсе яңа иҗтимагый хәрәкәт барлыкка килү һәм яңа иҗтимагый идея формалашу өчен, нигез булып тора. Фәннәрдә прогресска ирешү, мәдәниятне яңарту, татар халкының милли иреккә ирешү турындагы өметләре, мәктәп кемнеке генә булса да, җәдитчелеккә юнәлдерә.

Н. Исәнбәт фикеренчә, җәдитчелекне мәгърифәтчелектән аерып карарга ярамый. Татар халкы мохитендә әлеге сүзләр синонимнар буларак кулланыла.

Мәкаләләрендә Н. Исәнбәт «революцион демократик хәрәкәт» – җәдитчелекне – «зарарлы идеология» – пантюркизм һәм панисламизм белән тиңләштергән һәм либералларның кадимчеләрдән бердәнбер аермасын бары тик аларның милли буржуазия ихтыяҗларын кайгыртуында күргән М. Гайнуллин белән бәхәсләшә [Гайнуллин, С. 16]. Мәрҗанине буржуаз-либераль идеолог дип сурәтләгән положение аңа бигрәк тә ошамый [Гайнуллин, С. 11].

Тарихи гаделлекне торгызырга тырышып, Н. Исәнбәт 1940–1950 елларда җәдитчелеккә каршы күтәрелгән барлык гаепләмәләрне бер-бер артлы кире кага. Галим җәдитчеләр һәм кадимчеләр арасындагы бәхәсләрне киләксез бер эш, эшсезлектән интеккән милли буржуазия уйланмасы дип санаучыларны кискен тәнкыйтьли. Н. Исәнбәт прогресска юнәлеш тоткан татар халкының төрле катлам вәкилләре кадимчелек идеологиясенә каршы чыгыш ясый дип белдерә. Татар яшьләренең милли үзаң күтәрелеше дулкынында татар мәгърифәтен һәм мәдәниятен яңартырга омтылуын болай сурәтли: «Һәм, билгеле, татар яшьләре шул мөмкинлекләр мәйданына атылалар, мәйданы булмаса, анысын да үзләре ясыйлар. Шул мөмкинлекләр юлында үзләренең талант-сәләтләрен ача башлыйлар. Берләре – уку-укытучы педагог, икенчеләре гыйльми-фәнни әсәрләр, дәреслекләр яза, өченчеләре –әдәбият-матбугат кешеләре. Һәркемгә эш». [Исәнбәт, Мәгърифәт – Җәдид, Б. 34].

Галим фикенчә, кадимчеләр һәм җәдитчеләр арасындагы аерманы аларның киенү рәвешенә генә кайтарып калдырырга ярамый. Бу иске белән яңа көрәше була. Феодаль идеология тарафдарлары булган кадимчеләр мәдрәсәне мулла-мөэзиннәр әзерләү урыны дип күрә, хуҗалык эшчәнлеген искечә алып бара, халыкның артта калганлыгыннан файдалана. Менә шуңа күрә алар белән көрәшкә Ватаннары турында уйлаган, халкын яраткан, прогресс һәм мәгърифәтчелеккә омтылган төрле катлам вәкилләре күтәрелә.

Н. Исәнбәт татар җәдитчелеге үсешендә ике этапны аерып чыгара. Беренче этапта (XIX гасыр ахыры – 1905 ел) бу хәрәкәт буржуаз-мәгърифәтчел хәрәкәт төсен ала һәм милли үзаң үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килә. Хәрәкәтнең нигезен чит илдә яисә рус телендә белем алган укытучы-мөгаллимнәр, алдынгы карашлы муллалар һәм химаяче сәүдәгәрләр тәшкил итә. Алар тырышуының нәтиҗәсе булып милли мәгариф системасының реформасы тора.

Икенче этап 1905 ел инкыйлабыннан соң башлана. Бу вакытта җәдитчелек, агым буенча баруыннан котылып, «ислахчы»лар – революцион-демократик яшьләр җитәкчелегендә көчле массакүләм иҗтимагый хәрәкәткә әверелә. Бу этапта җәдитчеләр чынбарлыктан канәгатьсез булуларын революцион характердагы эш ташлаулар, бергәләшеп мәдрәсәдән китүләр белән чагылдыра. Галим фикеренчә, 1917 елга җәдитчелек хәрәкәте туктатыла диярлек, мәгариф системасын контрольдә тоту дәүләт карамагына күчә һәм дөньяви төс ала.

Н. Исәнбәт җәдитчелеккә каршы булганнар рәтенә Ишми-ишанны (Динмөхәммәтовны) һәм аның фикердәшләрен, донослар язып, пантюркизм белән көрәшү шигаре астында хакимиятне җәдиди мәдрәсәләрне юкка чыгаруга этәргән татар провокатор-карагруһчыларын кертә.

Н. Исәнбәт фикеренчә, реформалар нәтиҗәсендә җәдиди мәдрәсәләр татар милли интеллигенциясен әзерләү урынына әверелә. Үз китабында ул, С. Кудашка сылтама ясап, «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаучылар исемлеген анализлый: «“Галия” мәдрәсәсе 13 ел яшәп (1906-1919), аны 1500 шәкерт тәмамлаган, шулардан барлыгы 27 кеше мулла булган. Сәйфи үзе белгән 100 кешедән 57 се – КПСС члены, 20 се – профессионал язучы һәм социал реализмчылар, 28 кеше – журналист, фронт газеты редакторлары, 58 е – профессор, доктор һәм кандидат наук, 6 сы – агроном, 3 се –инженер, 3 се – юрист, 4 се – дипломат, 6 сы – татар-башкорт, казакъ республикаларында мәгариф

министрлары, 2 се – артист, берсе – композитор, калганнары – укытучылар» [Исәнбәт, Мәгърифәт – Җәдид, Б. 39].

Н. Исәнбәт татар җәдитчелеген бәяләгәндә вульгар-социологик формалаштырулар куллануга каршы чыга. Галим җәдитчелеккә каршы куелган күпләгән гаепләмәләрнең урынсыз булуын тикшерә һәм дәлилли:

а) пантюркизм белән бәйләнеше;

Җәдитчелек өчен сәяси проблема булып, аның нигез салучысы – туган иленнән 1944 елда депортацияләнгән һәм 1967 елда гына өлешчә реабилитацияләнгән кырым татары Исмәгыйль Гаспралы шәхесе тора. Сугыштан соңгы чорда СССР җәдитчелекнең бик күп вәкилләре белем алган Төркия белән начар мөнәсәбәттә була.

Татар галиме, бу каршылыклы моментларны урап узарга тырышып, милли мәгариф системасын яңартуның чишмә башында Исмәгыйль Гаспралы түгел, ә, иң беренче чиратта, татар мәгърифәтче-галимнәре Г. Курсави, бертуган Хәлфиннар, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, татар мәдрәсәсенә реформа ясарга җыенган бертуган Фәезхановлар торганлыгына басым ясый [Исәнбәт, Җәдитчелек, Б. 15-16]. Н. Исәнбәт фикеренчә, татар әлифбаларын язучы М. Ишмөхәммәтов белән Г. Баруди «аваз методы»н гамәлгә кертү вакытында, Исмәгыйль Гаспралы әлифбасыннан бигрәк, Европа галимнәре тәҗрибәсенә, аерып алганда, К. Д. Ушинский казанышларына нигезләнә. Галим И. Гаспралыны, тел берлеге нигезендә, төркиләрнең берләшүе турында хыялланган «Тәрҗеман» газетасы мөхәррире буларак характерлый. Галим фикеренчә, татар мәгърифәтчеләре Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри һ.б. 1880 нче еллардан, милли мәгариф системасын рус гимназияләре һәм университетлары үрнәгендә реформалаштыруга юнәлтелгән проектлар тудырып, китаплар нәшер итеп, чынлыкта татаризм идеяләрен чынга ашыралар.

Бербөтен төрки тел тарафдарлары булып, галимнәр фикеренчә, җәдитчеләр түгел, ә үзләрен «мөселманнар» дип атаган кадимчеләр чыгыш ясый [Исәнбәт, Мәгърифәт – Җәдид, Б. 43]. Кадимчеләр Европа уку-укыту системасы белән көрәшәләр, алар Европача белем алуның үзләрен кәферләргә әверелдерүеннән һәм руслаштырудан куркалар [Исәнбәт, Мәгърифәт – Җәдид, Б. 56-61].

б) панисламизмда гаепләү;

Н. Исәнбәт фикеренчә, җәдитчелекнең мәдәни-мәгърифәтчел хәрәкәт буларак меңьеллык тарихы бар, һәм ул 1905 елда төзелгән, алпавытлар һәм эре буржуазия мохитеннән чыккан мөселман кадетларыннан торган, «хәрәкәтләре 1905-1907 нче еллар арасында булган һәм революция куркынычы бетеп реакция җиңүе белән үзе дә беткән» «Мөселман иттифакы» партиясе белән берничек тә бәйле түгел [Исәнбәт, Җәдитчелек, Б. 17-18]. Галим ассызыклавынча, 1905 елдан соң җәдитчелек хәрәкәтен социал-демократлар партиясе тарафдарлары Х. Ямашев, Г. Колахмәтов һ.б. контрольдә тота башлый. Алга таба алар төрле партия тарафдарларына әверелә: сул социал-демократлар («уралчылар»), уң социал-демократлар («азатчылар»), эсерлар («таңчылар»). Алдынгы татар яшьләре тарафдарлары, «Ислах» комитеты төзеп, мәдрәсәләр челтәрен контрольдә тота башлыйлар. Шәкертләрнең революцион стачкалары һәм забастовкалары, татар телендәге алдынгы вакытлы («Фикер» газетасы, «Яшен», «Карчыга», «Чүкеч» журналлары) басмалар нәшер итүләре артында нәкъ менә шушы көчләр тора да инде. Н. Исәнбәт фикеренчә, алар «Иттифакъ әл-мөслимин» либераль партиясенә каршы уңышлы көрәш алып баралар [Исәнбәт, Мәгърифәт–җәдид, Б. 45]. Г.Тукай, М.Гафури, Ф.Әмирхан, Г.Колахмәтов, Г.Ибраһимов кебек үзләрен җәдитчеләр дип игълан иткән язучылар татар реалистик әдәбиятын үстерүгә искиткеч зур өлеш кертә. Н. Исәнбәт җәдитчеләрнең милли басмаларны үстерүдәге ролен ассызыклый. Җәдиди мәктәпләрне тәмамлаучылар Октябрь инкыйлабыннан соң сәяси агитаторлар, Кызыл Армия комиссарлары рәтләрен тулыландырып, фронт газеталары чыгаруда актив катнашалар.

Н. Исәнбәт, татар язучыларының әсәрләрен мисалга китереп, татар җәдитчелегенең панисламизмга бәйлелеген инкяр итә, бу күренешнең аларда кискен тәнкыйтьләнүен күрсәтә (Г. Тукай «Китмибез», «Вакыт»; Г. Ибраһимов «Без татарбыз») һәм нигез салучылары Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри булган татаризм идеяләренең татар халкы мохитендә алга таба да таралуын дәлилли [Исәнбәт, Мәгърифәт–җәдид, Б. 46]. Татар галиме җәдитчелекнең панисламизм һәм пантюркизм белән бәйләнешен Ишми ишан һәм аның тарафдарлары теләге белән оештырылган суд хөкеме дәлилли алмавына игътибар итә. [Исәнбәт, Мәгърифәт–җәдид, Б. 50].

в) «җәдитчелек – контреволюцион хәрәкәт».

Н. Исәнбәт җәдитчелекне «өстән төшерелгән» ике канатка бүлүгә кискен каршы чыга.

Б.Г. Гафуров (Гафуров) һәм аның фикердәшләре белән каршылыкка кереп, татар галиме татар җәдитчелеген мәгарифне Европа үрнәге буенча реформалаштыруга һәм татар әдәбиятын һәм мәдәниятен модернизацияләүгә юнәлтелгән мәдәни-агарту хәрәкәте дип саный. Татар галиме фикеренчә, үзенең эчке каршылыгы аркасында, «өстән» төшерелгән «аракчеевщина» концепциясе милли мәгариф системасына сизелерлек зыян китерәчәк, чөнки ул җәдитчелек чорында милли мәдәнияттә хәлләрнең ялган картинасын тудырырга ярдәм итә.

Н. Исәнбәт татар галимнәренең Урта Азия җәдитчелеген анализлаганда кулланыла торган гаепләү «ярлыкларын»ың сукырларча күчермәсенә каршы чыга.

Галим-энциклопедист милли тарихны фальсификацияләүгә һәм үткәннең мәдәни потенциалын игътибарсыз калдыруга каршы чыгыш ясый. Ул шәхес культы чорында җибәрелгән, Ленин милли сәясәтенә каршы килгән идеологик хаталарны җиңү зарурлыгына басым ясый.

Н. Исәнбәтнең җәдитчелеккә багышланган мәкаләләре татар тарихындагы мәдәни-мәгърифәти хәрәкәтне өйрәнү өчен мөһим чыганак булып тора. Ул милли интеллигенциянең иҗтимагый-мәдәни тормышны либерализацияләүгә юнәлгән өметләрен дәлилли. Булган материалларны анализлап, без шундый фикергә киләләбыз: Н. Исәнбәт җәдитчелек турындагы бәхәсләрнең актив катнашучысы була, ул катгый партия контроле шартларында рәсми кабул ителгән карашларга каршы барырга да курыкмый. Татар энциклопедист галиме үз мәкаләләрендә җәдитчелек үсеше өчен кирәкле алшартларны карап уза, аның ике этап дәвамындагы үсеш үзенчәлекләрен кыскача анализлый, бу мәдәни-мәгърифәти хәрәкәтнең милли үзенчәлеген ача, җәдитчелекне күренеш буларак дискредитацияләүгә юнәлгән фальсификацияләрне кире кага. Н. Исәнбәтнең җәдитчелек турындагы бәхәсләрдә актив катнашуы – аның батыр гражданлык позициясенең чып-чын дәлиле.

**Әдәбият**


*Госманов М.* Аксакаллар мәҗлесеннән. Нәкый Исәнбәт (1899-1992) // Госманов М.Г. Хәтер мизгелләре : истәлекләр. Казан: Татар. кит.нәшр., 2019. Б. 174-199.

*Ибраһимов Г.* Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре //Аң. 1915. № 1. С. 7-19.

*Ибраһимов Г.* Бөек остазымызнын тарихы бер тәнкыйде // Аң. 1915. № 2. С. 39-43.

*Исәнбәт Н.* Мәгърифәт–җәдид // Н. Исәнбәтнең шәхси архивы, кульязма. 40 б., датасыз. Татар. телендә.

*Исәнбәт Н.* Җәдидчелек // Н. Исәнбәтнең шәхси архивы, кульязма. Татар. телендә. 30 б.

*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. Казан: Татар. дәүләт нәшр. басмасы, 1926. 300 б.

*Таһиров И.Р.* Алтын Урда һәм «Идегәй» дастаны // Казан утлары. 1993. №11. Б. 145-147.

*Шафиков К.* Тарихи чынлык өчен // Совет әдәбияты. 1944. №10. Б.3-8.

*Валидов Д.* Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). Москва; Петроград: Гос. изд-во, 1923. 106 с.

*Гайнуллин М.Х.* Каюм Насыров и просветительское движение среди татар. Казань: Таткнигоиздат, 1955. 96 с.

*Гафуров Б.Г.* Успехи национальной политики КПСС и некоторые вопросы интернационального воспитания // Коммунист. 1958. № 11.

Из постановления бюро Татарского обкома ВКП (б) «Об ошибках в учебнике литературы для 8 класса татарских школ» // История татар с древнейших времен: 7 т. – т. 7. Казань: Институт истории Ш. Марджани АН РТ, 2013. С.861-862.

*Мухаметов Х.Г.* Просветительские идеи в татарской литературе последней четверти XIX века: Автореф. дис. … канд. филолог. наук. – Казань: КГУ, 1953. 17 с.

Постановление ЦК ВКПб от 9 августа 1944 г. «О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы в Татарской партийной оргвнизации» // КПСС в резолюциях и решениях съездов и пленумов ЦК в 16 т. Т.7. (1938-1945). М.: Политиздат, 1985. С.513-520.

Революция 1905-1907 гг. в национальных районах России [Текст]: Сборник статей / Под ред. Л. М. Иванова [и др.]; Акад. наук СССР. Ин-т истории. Москва: Госполитиздат, 1955. 832 с.

*Султанбеков Б.* «Идегей», Сталин и наше время // Татарстан. 1992. №7-8. С.32-47.

*Фасеев К.Ф.* Из истории татарской передовой общественной мысли. (Вторая половина XIX – начало XX в.). Казань: Таткнигоиздат, Ред. полит. и ист. лит., 1955. 280 с.

*Хабутдинов А., Хабутдинова М.* Образ Наки Исанбета в татарской прозе // Филология и культура. PHILOLOGY AND CULTURE. 2019. №4(58). С.191-201.

*Хаплехамитов Р.Б.* Татарская творческая интеллигенция и власть (1944-1965). Казань: «Слово», 2011. 152 с.

# «ВОПРОС ДЖАДИДИЗМА ЯСЕН, НО ИСАНБЕТ ХОЧЕТ ЗАПУТАТЬ ЕГО ПО-СВОЕМУ»: ИЗ ИСТОРИИ ДИСКУССИИ О ДЖАДИДИЗМЕ В 1950–1960 ГГ.

**Айдар Юрьевич Хабутдинов,**
Казанский филиал Российского государственного университета правосудия,
Россия, 420088, г. Казань, ул. 2я Азинская, д. 7а,
aihabutdinov@mail.ru.

В статье рассматривается концепция джадидизма, изложенная в трудах ученого-энциклопедиста Наки Исанбета (1899–1992). Материалом исследования послужили статьи писателя, посвященные джадидизму. В 1930–1950-е гг. из-за своих взглядов Н. Исанбет не раз был подвергнут гонениям со стороны властей. Писатель позволил себе открытую критику спущенной сверху концепции джадидизма. Статьи Н. Исанбета о джадидизме – свидетельство надежд национальной интеллигенции на либерализацию общественно-культурной жизни.

**Ключевые слова:** татарская литература, Н. Исанбет, татарское медресе, мир шакирдов, повседневность.